**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.05.2019 Балык Бистәсе штп. № 175пи

“2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү” муниципаль программасын раслау турында

2007 елның 24 июлендәге “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 209-ФЗ номерлы Федераль законны, 2010 елның 21 гыйнварындагы “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 7-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. “2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү” муниципаль программасын расларга (теркәлә) (алга таба – Программа).

2.Программаның заказ бирүче-яраштыручысы итеп Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә Программа чараларының үтәлүен һәм җирле үзидарә органнары, кызыксынучы оешма һәм учреждениеләр тарафыннан аны тормышка ашыру буенча эшчәнлекне яраштыруны тәэмин итәргә.

4. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 11 августындагы “2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү” муниципаль программасын раслау турында” 123пи номерлы карарын;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 августындагы “ Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 11 августындагы 123пи номерлы карары белән расланган “2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү” муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында” 208пи номерлы карарын.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 23 маендагы
175 пи номерлы карары белән
расланды

# 2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү ПРОГРАММАСЫ

2019 ел

**Эчтәлек**

1. Муниципаль программаның паспорты
2. Кыскача кереш
3. Программаның гомуми өлеше:
 3.1.Программаның максаты һәм бурычлары
 3.2.Агымдагы вазгыятькә анализ, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары үсеше проблемаларын бәяләү
 3.3.Икътисад секторларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү:
 3.3.1. Агросәнәгать комплексында КУЭны (кече, урта эшкуарлык) үстерү
 3.3.2. Туристлык өлкәсендә КУЭ ны үстерү
 3.3.3. Куллану базарын үстерү
 3.3.4.Яшьләр арасында эшкуарлыкны үстерү
 3.3.5.Сәнәгать мәйданчыкларын үстерү һәм резидентларны җәлеп итү
 3.3.6.Үзмәшгуль халык өчен программа булдыру
4.Инвестицияләр җәлеп итүчәнлекне бәяләү, эшкуарлыкны үстерү юнәлешләре һәм конкрет чаралар исемлеге
5. Программаны чыганаклар белән тәэмин итү
6. Хәтәр тәвәккәллекне (риск) бәяләү, аларны киметү буенча чаралар
7.Программаның планлаштырылган икътисади нәтиҗәлелеге, программа белән идарә итү һәм тормышка ашыруга контроль
8. Йомгаклар һәм кушымталар

## 1. Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү (алга таба – Программа) |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге |

| | |
|---|---|
| Программаның максаты һәм бурычлары | Муниципаль программаның максаты: Инновация икътисады формалашуның әһәмиятле компоненты буларак, кече һәм урта эшкуарлыкның нәтиҗәле эшләве һәм үсеше өчен шартлар булдыру, шулай ук аның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының социаль-икътисади үсеше бурычларын хәл итүдәге өлешен арттыру<br>Муниципаль программаның бурычлары:<br>1. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү өчен инфраструктура объектлары булдыру һәм үстерү;<br>2. Яңа гына керешкән эшкуарларга ярдәм итү;<br>3. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә норматив хокукый җайга салуны (көйләүне) камилләштерү;<br>4. Кадрлар потенциалын ныгыту, эшкуарның уңай образын (тибын) булдыру;<br>5.Сәүдә һәм куллану базарын үстерү. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2019-2023 еллар |
| Программаны үтәүчеләр | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге |
| Программаны финанслауның күләмнәре һәм чыганаклары | 1 сценарий Финанслауның гомуми күләме (җирле бюджет) 150 мең сум, шул исәптән еллар буенча:<br>2019 – 20 мең сум<br>2020 – 25 мең сум<br>2021 – 30 мең сум<br>2022 – 35 мең сум<br>2023 – 40 мең сум<br>2 сценарий Финанслауның гомуми күләме (фб һәм рб, фондлар, эшкуарларның үз средстволары) 343 млн. сум, шул исәптән еллар буенча:<br>2019 – 51 млн. сум<br>2020 – 64 млн. сум<br>2021 – 69 млн. сум<br>2022 – 76 млн. сум<br>2023 – 83 млн. сум |

| | |
|---|---|
| Программаның үтәлешенә контроль | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны тормышка ашыруның төп нәтиҗәләре | Тулы күләмдә Программаны тормышка ашыру 2023 ел азагына ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>1.Гамәлдәгеләрен саклап калырга һәм яңа кече һәм урта предприятиеләр булдырырга, алар үз чиратында кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә эш урыннарын арттырырга мөмкинлек бирәчәк.<br>2.Кече һәм урта эшкуарлыкның эчке тулай продуктка гомуми кертеме (өлеше) 5,7 процент пунктына үсәчәк.<br>3.Катнашучылары фәкать КУЭ субъектлары гына булган сатып алулар өлеше 59 процентка чаклы үсәчәк.<br>4. Кече һәм урта эшкуарлыкта мәшгуль хезмәткәрләрнең |

| | |
|---|---|
| | хезмәт хакы дәрәҗәсен минималь куллану бюджетыннан түбән булмаган күләмдә саклап калуга. |

## 2. Кыскача кереш

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү хуҗалык итүнең хәзерге заман базар системасы формалашуның индикаторы булып тора. Хәзерге вакытта кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү мәсьәләләре аеруча зур әһәмияткә ия, чөнки кече һәм урта эшмәкәрлекне тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру финанс кризисы нәтиҗәләрен йомшартырга, өстәмә мәшгульлекне һәм җитештерүне арттыруны тәэмин итәргә мөмкин.

Кече һәм урта эшкуарлыкның район икътисадына керткән өлеше елдан-ел зуррак була бара. Чыгарыла торган продукциянең, эш һәм хезмәт күрсәтүләрнең күләме үсә, яңа технологияләр кертү хисабына аларның ассортименты һәм сыйфаты яхшыра. Барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым килерләре арта, эшкуарларның эшмәкәрлекне цивилизацияле алып баруга омтылышлары һаман саен күбрәк күзгә ташлана бара.

Хәзерге мизгелдәге иң мөһим бурыч булып кече һәм урта эшкуарлык субъектларын арттыру, районыбызда көн итүчеләргә аеруча зарур булган эш урыннары булдыру өчен инвестицияләр җәлеп итү тора.

Бүгенге көндә икътисадны үстерүнең төп бурычлары булып тора:

-инвестицияләр җәлеп итү;

- кулланучылар кооперациясен үстерү;

- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар булдыру;

- яшь кадрлар әзерләү.

Үзебезгә бурыч куябыз: район биләмәсендә бер генә квадрат метр мәйдан да һәм бер генә квадрат метр җир дә буш торырга тиеш түгел. Бүгенге көндә район территориясендә сәнәгать мәйданчыклары төзү белән ныгытып шөгыльләнәбез.

2007 елның 24 июлендәге “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 маддәсен тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында түбәндәге өлкәләрнең берсендә эшчәнлекнең өстенлекле төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларына:

сәнәгать (эшкәртү) җитештерүе;

резина һәм пластмасса эшләнмәләре җитештерү;

экологик максатлар өчен җиһазлар җитештерү;

халык сәнгать (нәфис) кәсепләрен (нәфис чүкү) үстерү;

авыл хуҗалыгы продукциясе, халык куллануы товарлары һәм туклану продуктлары җитештерү, аларны эшкәртеп озак срокка саклана торган товарларга әйләндерү һәм реализацияләү;

агач эшкәртү һәм агачтан эшләнмәләр җитештерү;

балык үстерү, эшкәртү һәм балык продукциясе реализацияләү;

логистика үзәкләре (склад инфраструктурасы)

әлеге муниципаль программа нигезендә ташламалы шартларда арендага торак пунктларның план нигезендә җитештерү эшчәнлеге күз алдында тотылган файдалануга рөхсәт ителгән җирләре категориясеннән җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруга , яшелчәчелек, бакчачылык, индивидуаль торак төзелешенә аталган җир кишәрлекләреннән гайре) бирү рәвешендә мөлкәти ярдәм гамәлгә ашырыла.

Әлеге үзидарәлек программасының эшчәнлекнең өстенлекле төрләрендә күрсәтелгән җир кишәрлекләре максатчан билгеләнеш буенча файдаланылырга тиеш.

Әлеге үзидарәлек программасының эшчәнлекнең өстенлекле төрләрендә күрсәтелгән җир кишәрлекләрен кече һәм урта эшкуарлык субъектына арендага бирүнең ташламалы шартлары булып биш елдан да ким булмаган срокка төзелгән аренда шартнамәсе буенча җир кишәрлеге өчен еллык аренда түләве зурлыгын түбәндәге күләмнәрдә билгеләү тора:

аренданың беренче елында – аренда шартнамәсендә тәгаенләнгән еллык аренда түләве күләменең 20 проценты;

аренданың икенче елында- аренда шартнамәсендә тәгаенләнгән еллык аренда түләве күләменең 40 проценты;

аренданың өченче елында- аренда шартнамәсендә тәгаенләнгән еллык аренда түләве күләменең 60 проценты;

аренданың дүртенче елында- аренда шартнамәсендә тәгаенләнгән еллык аренда түләве күләменең 80 проценты;

аренданың бишенче елында- аренда шартнамәсендә тәгаенләнгән еллык аренда түләве күләменең 100 проценты.

Без барыбыз да районга яңа нәтиҗәле эшкуарлык җәлеп итү белән кызыксынабыз.

## 3. Программаның гомуми өлеше

### 3.1. Программаның максаты һәм бурычлары

Муниципаль программаның максаты: Инновация икътисады формалашуның аеруча әһәмиятле компоненты буларак, кече һәм урта эшкуарлыкның нәтиҗәле эшләве һәм үсеше өчен шартлар булдыру, шулай ук

аның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының социаль-икътисади үсеше бурычларын хәл итүдәге өлешен арттыру.

Муниципаль программаның бурычлары:

1. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү өчен инфраструктура объектлары булдыру һәм үстерү;

2. Яңа гына керешкән эшкуарларга ярдәм итү;

3. Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә норматив хокукый җайга салуны камилләштерү;

4. Кадрлар потенциалын ныгыту, эшкуарның уңай образын (тибын) булдыру;

5.Сәүдә һәм куллану базарын үстерү.

### 3.2. Агымдагы вазгыятькә анализ, Балык Бистәсе муниципаль районында КУЭ субъектлары үсеше проблемаларын бәяләү

Бүгенге көндә районда 122 кече һәм микропредприятие, 2 урта һәм 559 индивидуаль эшкуар үзенең хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыра. Индивидуаль эшкуарларны исәпкә алып, районның кече һәм урта предприятиеләрендә эшләүчеләрнең исемлек буенча уртача саны 1,9 меңне тәшкил итә.

Конкрет цифрларга тукталсак: 2018 ел өчен тулай территориаль продукт күләме алдан бәяләүләр буенча 6 млрд. 900 миллион сум тирәсе тәшкил итә. Узган ел йомгаклары буенча 6 миллиард 43 миллион сум тәшкил итте. Шуларның авыл хуҗалыгына 1 миллиард 978 миллион сумы туры килә. Һичшиксез, мондый югары күрсәткечләргә ирешүнең гаять зур өлеше кече һәм урта эшкуарлык субъектларыныкы.

Хуҗалык итүнең кече формаларын үстерү актив рәвештә алып барыла. Район республикада хуҗалык итүнең кече формаларын үстерү буенча алдынгы позицияләрне били. Районда 95 авыл хуҗалыгы берләшмәсе эшли, шулар арасыннан 15 е – җаваплылыгы чикләнгән һәм акционерлык җәмгыять, 80е – крестьян-фермерлык хуҗалыгы, алар арасында 45 гаилә фермасы һәм КФХ базасында оештырылган 2 авыл хуҗалыгы кооперативы.

Гомумән, 2018 елда район территориясендә 96 индивидуаль эшкуар һәм 17 крестьян-фермерлык хуҗалыгы эш башлады. Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан 53,5 млн. сум күләмендә салым керде.

Авыл хуҗалыгын үстерү белән беррәттән районның икътисади нәтиҗәлелегенә кече һәм урта эшмәкәрлекнең сәнәгать предприятиеләре эше дә сәбәпче булды.

2018 ел бәяләве буенча кече һәм урта предприятиеләрнең әйләнеше 2723 млн. сум тәшкил итә, ә ул узган елның шул чорындагыга караганда 4 % ка артык.

Район буенча кече предприятиеләрдә 1 хезмәткәрнең уртача хезмәт хакы 13 261 сум тәшкил итте, ә ул узган елның шул чорындагыга караганда 10,4 % ка күбрәк.

Эшкуарлык төрләре структурасында иң зур урынны сәүдә, гомуми туклану һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре били (40%), авыл, урман хуҗалыгы, ау, балык тоту һәм балыкчылык өлеше – 22%, транспорт һәм элемтә – 18%, төзелеш – 5%, эшкәртү производстволары – 4%, бүтән эшчәнлек – 11%.

Балык Бистәсе муниципаль районында КУЭ үсеше проблемалары:

-халыкның эшлекле активлыгының түбән булуы;

-финанс чыганакларының булмавы;

-хезмәт ресурслары сыйфатының түбән дәрәҗәсе.

## 3.3. Балык Бистәсе муниципаль районында икътисадның төрле сайланган секторларында КУЭ ның үсеше

### 3.3.1. Агросәнәгать комплексында КУЭ ның үсеше

Агросәнәгать комплексы (алга таба – АСК) – авыл хуҗалыгы чималы җитештерү һәм эшкәртүгә, шулай ук соңгы куллану өчен авыл хуҗалыгы продукциясе алуга юнәлдерелгән берничә икътисади тармакны берләштерүче тармакара комплексларның иң эреләренең берсе. АСК составына авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать тармаклары, алар белән турыдан-туры бәйләнгән – авыл хуҗалыгы чималын һәм продукциясен ташу, саклау, эшкәртү һәм ваклап (данәләп) һәм күмәртәләп (күпләп) сатып алучыга җиткерү керә.

Заманча базар шартлары вазгыятен анализлап шуны расларга мөмкин: АСК составына керүче предприятиеләрнең бербөтен икътисады юк. АСК ның эшләвендә катлаулылык күп очракта килеп туган проблемаларның сәбәбе булып тора, шулай ук тармакара элемтәләргә тәэсир итә. Әлеге проблеманы юк итәргә кирәк, чөнки АСК башка өлкәләр продукциясен иң төп кулланучыларның берсе булып тора, гражданнар өчен күп санда эш урыннары булдыра.

Анатыш авыл җирлеге территориясендә Володин Николай Вячеславович ның КФХ ы 24 гектар мәйданда карлыган үстерү белән шөгыльләнә. Агымдагы елда 300 кг уңыш җыеп алды, инвестицияләр җыенысы 10 млн. сум тәшкил итте, 3 эш урыны булдырылды, перспективада 10 кешегә җиткерү нияте.

Олы Солтан авыл җирлеге биләмәсендә Сәлахов Рамил Камилевич КФХ ы 6 га җирдә алма һәм җир җиләге үстерү белән шөгыльләнә. Җир җиләгенең беренче уңышы 1,5 тонна тәшкил итте, узган ел көз 12 сортта алмагачлар утыртты, бакча кишәрлеге мәйданын 30 га га җиткерергә планлаштыралар. Перспективадагы ниятләрендә үстерелгән продукцияне эшкәртү буенча цех булдыру. Белдерелгән инвестицияләр суммасы 11 млн. сумны тәшкил итә, бүгенге көнгә 3,5 млн. сумы үзләштерелгән. 10 эш урыны булдыру планлаштырыла.

"Кулон Агро" ҖЧҖ 500 баш сыерга исәпләнгән заманча терлекчелек комплексы төзүне оештырды, швед токымлы 350 баш тана кайтартты. Агымдагы елның язында терлекчелек комплексының өстәмә 500 башка исәпләнгән икенче чиратын төзү башланды. Бүгенге көндә 195 млн. сумлык инвестицияләр кертелде. Уртача хезмәт хакы 20 000 сумнан ким булмаган өстәмә 40 эш урыны булдырылачак. Инвестицияләр күләме 220 млн. сум тәшкил итәчәк.

Агросәнәгать комплексындагы КУЭ саны

| Күрсәткеч | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|
| КУЭ саны | 122 | 128 | 132 | 135 | 140 | 143 |

### 3.3.2. Туристлык өлкәсендә КУЭ үсеше

Балык Бистәсе муниципаль районының туристик потенциалын үстерү буенча районның хакимият органнары тарафыннан туризм өлкәсендә КУЭ ны үстерү максатыннан төрле республика һәм Россия күргәзмәләрендә даими рәвештәге таләпләр, масштаблы үзенчәлекле чаралар үткәрү исәбенә планлы эш алып барыла.

2014 елда "Кыргый ферма" КФХ ҖЧҖ инвестор белән берлектә "Кыргый ферма" эко-туристик паркы" проектын тормышка ашырырга кереште. Бүгенге көндә парк территориясендә 100 баштан артык кыргый хайван (тимгелле боланнар һәм мараллар) асрала. Әлеге яңа юнәлеш район өчен эко-туризмны һәм авыл туризмын үстерергә мөмкинлек бирәчәк.

Туристик өлкәдә КУЭ саны

| Күрсәткеч | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|
| КУЭ саны | 1 | 2 | 2 | 3 | 3 | 4 |

### 3.3.3.Куллану базарының үсеше

2019 елның 1 гыйнварына булган торыш буенча Балык Бистәсе муниципаль районында сәүдә эшчәнлеген 229 предприятие гамәлгә ашыра.

2018 елда 3 кибет ачылды. 2018 елда сәүдә предприятиеләренең товар әйләнеше 1 737 млн. сум тәшкил итте, узган ел дәрәҗәсенә үсеш 103 %, шулардан азык-төлек товарлары төркеменең товар әйләнеше 1389,8 млн. сум, азык-төлек булмаган товарлар төркеменең 347 млн. сум. Районның 1 көн күрүчесенә 2018 елда 68,3 мең сумлык товар реализацияләнгән.

Муниципаль район территориясендә азык-төлек булмаган товарлар төркемен реализацияләүче 1 базар урнашкан. 2018 елның 12 аенда базар сәүдәсенең товар әйләнеше 364,5 млн. сум тәшкил итте, 2017 ел белән чагыштырганда киму 4 %. Базарның товар әйләнеше муниципаль районның гомуми товар әйләнеше күләменең 21 %ын тәшкил итә.

Стационар сәүдә предприятиеләрендә эшләүчеләр саны 1007 кеше. Уртача хезмәт хакы 11 570 сум, узган елга караганда бу 111,6 % ны тәшкил тә.

Балык Бистәсе муниципаль районында базарларны исәпкә алып 13556,3 квадрат метр сәүдә мәйданы исәпләнә.Бер мең кешегә 533 квадрат метр сәүдә мәйданы туры килә.

Районда 560 урынга исәпләнгән 13 җәмәгать туклануы предприятиесе эшли. Ел дәвамында һәркем өчен мөмкинлекле җәмәгать туклануы предприятиесе ачылды. Җәмәгать туклануы предприятиеләренең товар әйләнеше 58,8 млн. сум тәшкил итте, узган ел дәрәҗәсенә карата үсеш 104 % булды. Җәмәгать туклануы предприятиеләрендә хезмәт куючылар саны – 52 кеше. Уртача хезмәт хакы 11215 сум, 2017 елга карата үсеш 111,2%.

Районда халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү буенча 29 предприятие эш алып бара.2018 елда әйләнеш 36 млн. сум тәшкил итте, узган ел дәрәҗәсеннән үсеш – 101,8 %. Эшләүчеләр саны 71 кеше. Уртача хезмәт хакы 11 230 сум, үсеш 111,6 %.

Куллану базары үсешенең күтелгән күрсәткечләре

| Күрсәткеч | Еллар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Ваклап сату сәүдәсе әйләнеше, млн. сум | 1908,98 | 2031,06 | 2158,84 | 2266,78 | 2380,12 | 2499,13 |
| Халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күләме, млн. сум | 264,9 | 287,89 | 315,59 | 331,37 | 347,93 | 365,33 |

## 3.3.4. Яшьләр арасында эшкуарлыкның үсеше

Яшьләр эшкуарлыгы хәзерге заман җәмгыятенең мәнфәгатьләр үзәгендә тора, барлык халыкның тормышына кагыла. Нәкъ менә яшь кешеләр

уйлап табу һәм инновация эшчәнлеген башлап җибәрәләр: тикшерүләр төп идея һәм уйлап табуларның эре предприятиеләрдән һәм бизнеслары инде булган эшмәкәрләргә караганда яшьләр эшкуарлыкларыннан ешрак керүен күрсәтә. Инновацияләр мохитендә яшьләр эшкурлыгының иҗаты кулланучылар өчен яңа продукция һәм хезмәт күрсәтүләрнең таралуына булышлык итә.

Борисов Тимур Валерьевич, крестьян (фермер) хуҗалыгы (КФХ) төзеп, африка сомы үстерү белән шөгыльләнә башлады. Проект 2018 нең гыйнварында башлап җибәрелде. Расланган инвестицияләр җыенысы 3,54 млн. сум тәшкил итте. Инде бүгенге көнгә 1 500 кг балык үстерелгән. Балык эшкәртү өчен җиһазлар алынган. Параллель рәвештә балыкларны кабат җитештерү – маймычлар үстерү алып барыла. Проектка 1,5 млн. сум акча средстволары салынган, 2 эш урыны булдырылган.

Яшьләр арасында эшкуарлыкны үстерүнең көтелгән күрсәткечләре

| Күрсәткеч | Еллар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Яшь эшкуарлар саны, берәмлек | 6 | 8 | 10 | 12 | 14 | 16 |

### 3.3.5. Сәнәгать мәйданчыкларын үстерү һәм резидентлар җәлеп итү

Муниципаль район территориясенә инвесторларны тарту буенча актив эш алып барыла. 2018 елның апрелендә инвестор “Балык Бистәсе ХПП” ҖЧҖ икмәк кабул итү пунктын модернизацияләүгә тотынды. Әлеге проект буенча белдерелгән инвестицияләр җыенысы 80 млн.сум тәшкил итә.2018 елда 60 млн. сум капитал салынды. Территория асфальтланды, төяү линияләре торгызылды, су транспорты белән икмәкне Иран Республикасына озату өчен причалга ремонт үткәрелде. Шулай ук агымдагы елда предприятие территориясендә “Балык Бистәсе ХПП” ҖЧҖ якор резиденты белән 2018 елның 13 декабрендә “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы төзелде һәм аккредитацияләнде. Бүгенге көндә сәнәгать мәйданчыгының идарәче компаниясе белән “Рав-Агро” һәм “РС-Агро” ҖЧҖ ләре резидентларының хезмәттәшлек ниятләре турында килешүләре төзелде, мәйданчык территориясендә көнбагыш сыгу буенча цех торгызу турында “Казан май комбинаты” ААҖ белән сөйләшүләр алып барыла. 44 эш урыны булдырылды. Перспективада янәдән 30 эш урыны булдыру планлаштырыла.

“Фуд Альянс”ҖЧҖ төрек инвесторы агымдагы елда 100 га мәйданда теплица комплексы төзүгә керեште. Бүгенге көндә 2 га мәйданда җир җиләгенең беренче уңышын җыялар. Моннан тыш каен җиләге, пекин кәбестәсе, томат һәм кыяр үстерү белән шөгыльләнә. Агымдагы елда проектка 17 млн. сум кертелде, 15 эш урыны булдырылды, киләчәктә 40 эш

урынына җиткерү исәбе белән. Әзер продукцияне саклау өчен яшелчә саклагыч төзү планлаштырыла.

Якын киләчәктә якор резиденты “Фуд Альянс” ҖЧҖ белән “Татарстан гектары” проектын тормышка ашырырга планлаштырабыз. Проектның максаты: һәрбер теләге булган фермер кооперативка кереп җир җиләге, кура җиләге, карлыган үстерү белән шөгыльләнә ала торган 200 га мәйданлы җирдә кооператив төзү. Белдерелгән инвестицияләр җыенысы 70 млн. сум. Проект шулай ук җитештерелгән продукцияне эшкәртүне (ул – крафт-упаковка, крафт- компот һәм крафт-морс) үз эченә ала. Әлеге проектны тормышка ашыру өстәмә 100 эш урыны булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

Элеккеге кирпеч заводы территориясендә сәнәгать мәйданчыгы төзелешенә керештеләр. Бүгенге көндә тәүге резидент “Клариус” ҖЧҖ кларий җәене үрчетү буенча завод төзүгә тотынды. Капитал салу күләме 15 млн. сум тәшкил итә.

Сәнәгать мәйданчыклары саны

| Күрсәткеч | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Сәнәгать мәйданчыклары саны | 2 | 3 | 4 | 4 | 5 | 5 |

### 3.3.6. Үзмәшгуль халык өчен программа булдыру

Россия милли икътисады системасында мәшгульлекнең бер төре булып халыкның мөстәкыйль мәшгульлеге тора (алга таба – үзмәшгульлек). Төрле вакыт чорларында төрле шартларда аның таралу масштабы, икътисади тормыштагы роле һәм урыны минимальдән алып гаять әһәмиятлегә чаклы үзгәрде.

Үзмәшгуль гражданнарга керәләр: репетиторлар, фотографлар, тегүче, сапожник, хосусый водитель, җыештыручы, горничный, ремонтчы, няня, дизайнер, тәрҗемәче, балыкчы, ярминкә сәүдәгәре, журналист, копирайтер, программист, чәчтараш һәм маникюр остасы, хайваннар өчен гостиница ияләре һ.б.

Хакимиятнең җирле органнары хезмәт мөнәсәбәтләрен законлаштыру буенча, шул исәптән үзмәшгуль гражданнарга карата үзләренең эшчәнлекләрен гамәлгә ашыруга аларны шуннан соңгы теркәү белән актив ярдәм күрсәтәләр. Мондый эш формаларының берсе булып муниципаль район территориясендә формаль булмаган мәшгульлеккә мониторинг үткәрү тора.

Индивидуаль эшкуарларны да кертеп, кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә мәшгульләр саны

| 2019 елга үзмәшгуль гражданнарны теркәү буенча план күрсәткече бүленеше, кеше | Индивидуаль эшкуарларны да кертеп, кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә мәшгульләр саны, кеше (2024 елга үсә баручы йомгак белән) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2019,үзмәшгуль гражданнарның законлаштырылуын исәпкә алып | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| 336 | 2 251 | 2 290 | 2 332 | 2 358 | 2 390 | 2 456 |

## 4. Территориянең инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген бәяләү, эшкуарлыкны үстерү юнәлешләре һәм конкрет чаралар исемлеге

ББМР ның үзәге – Балык Бистәсе штп. – Татарстан Республикасы башкаласы Казан шәһәренә якын урнашкан район үзәкләренең берсе, бүгенге көндә Россия һәм чит илләр инвесторларын җәлеп итү өчен кирәкле барлык шартларга ия.

Җирле үзидарә органнарының икътисади сәясәт өлкәсендә төп бурычы булып икътисадны ныгыту һәм алга таба үстерү, предприятиеләрнең тотрыклы эшләве өчен уңайлы мохит булдыру, районда көн итүчеләрнең тормыш дәрәҗәсен яхшырту тора.

Район территориясендә районның социаль-икътисади үсеше өчен төп җәлеп итүче моментларының берсе булып тора:

- районның Чулман елгасының яр буенда урнашуы, район үзәге Балык Бистәсендә суда утыру тирәнлеге 9 м га кадәр булган күп йөк төяүче судноларны кабул итәргә сәләтле причал булу;

-“Казан” халыкара аэропортына якынлыгы (80 км);

-район территориясе аша федераль әһәмияттәге М-7 (Казан – Яр Чаллы) һәм Казан – Оренбург трассаларының узуы.

Балык Бистәсе муниципаль районы 1927 елда оеша, Татарстан Республикасының үзәк өлешендә Чулман елгасының уң як ярында урнашкан.Район көнбатыштан Лаеш, төньяктан Саба, көнчыгыштан Мамадыш районнары белән чикләнгән.Район территориясеннән Чулман елгасы һәм Чулманга коючы Бәтке, Әшнәк, Суша һәм Шумбут инешләре ага.

Район территориясенең мәйданы 2041,4 кв. км, шул исәптә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр мәйданы – 11465 кв. км. Район биләмәсендә 1 шәһәр һәм 26 авыл җирлеге урнашкан, районда барлыгы 77 торак пункт.

Район халкының гомуми саны 2018 ел башына 25440 кеше булды, шуларның 48% ы хезмәткә яраклы яшьтә, 28%ы – ул яшьтән өлкәнрәкләр һәм 16% ы – балалар. Милли составы: 78 % ы – татарлар, 19 % ы – руслар һәм 3 % ы – бүтән милләт вәкилләре.

Инвестицияләр җәлеп итү икътисадны үстерү һәм социаль мәсьәләләрне хәл итүнең зарур шарты булып кала бирә. 2017 елда финанслауның барлык чыганаклары исәбенә төп капиталга инвестицияләр күләме 1299,53 млн. сум тәшкил итте, 2018 елның 9 аена – 772,3 млн. сум.

2014 – 2018 елларда Балык Бистәсе муниципаль районына төп капиталга инвестицияләр күләме динамикасы

| Күрсәткеч | Еллар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 ( 9 ай эчендә) |
| Финанслауның барлык чыганаклары исәбенә төп капиталга инвестицияләр млн. сум | 654,68 | 907,97 | 1674,79 | 1299,53 | 772,3 |

Инвестицияләр структурасында төп өлеш сәнәгать предприятиеләренә туры килә, боларда инвестицияләр җитештерүне модернизацияләүгә һәм үстерүгә, җитештерү егәрлекләрен нәтиҗәле файдалануга юнәлтелгән.

## 5. КУЭ ны үстерү программасын чыганаклар белән тәэмин итү

Финанслауның барлык чыганаклары исәбенә Программаны тормышка ашыруның барлык чорына Программаны финанслауның ниятләнгән күләме – 343 млн. 150 мең сум, шул исәптән:

-150 мең сум күләмендә район бюджетыннан средстволар (Программа чараларын финанслау күләмнәре тиңдәшле финанс елына һәм план чорына район бюджетын формалаштырганда ел саен аныклана) КУЭ ка финанс ярдәме күрсәтүгә, ел саен үткәрелә торган конкурсларны уздыруга, эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктурасын үстерүгә һәм башка чараларны тормышка ашыруга юнәлтеләчәк;

-КУЭ субъектларының 343 млн. сум күләмендәге средстволары товарлар (эшләр, хезсәт күрсәтүләр) җитештерүне оештыру, үстерү һәм (яки) модернизацияләү максатларында җиһазлар алу (шул исәптән лизинг шартнамәләре буенча) белән бәйле чыгымнарны түләүгә юнәлтеләчәк.

## 6. Хәтәр тәвәккәллекләрне бәяләү, аларны киметү буенча чаралар

Балык Бистәсе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык үсешен әкренәйтүче түбәндәге проблемалар яшәп килә:

1) күп кече һәм урта эшкуарлык җитәкчеләренең һәм индивидуаль эшкуарларның хокук, финанс, салым законнары мәсьәләләрендә әзерлек дәрәҗәсенең түбән булуы;

2) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын социаль проблемаларны, беренче нәүбәттә халыкның мәшгульлеген хәл итү өчен йомшак файдалану;

3) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен кредит продуктларының югары процент ставкасы;

4) нык үскән инфраструктураның булмавы;

5) объектларны технологик тоташтыру буенча, ш.и. электроэнергияне, хезмәт күрсәтүләр бәһасенең югары булуы;

7) Балык Бистәсе штп. Һәм Татарстан Республикасы электрон мәйданчыкларындагы торгиларда (ачык базарларда) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының катнашу кыенлыклары;

8) “бер тәрәзә” принцибы буенча инвестиция проектларын озату (теркәү, булу) регламентының булмавы.

Моның белән бәйле рәвештә кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык итүнең моңа кадәр булган төбәк һәм дәүләт системасы белән бәйләп кече һәм урта эшкуарлыкка муниципаль ярдәмнең комплекслы системасын булдыру зарур.

## 7. Программаның планлаштырудагы икътисади нәтиҗәлелеге, программа белән идарә итү һәм тормышка ашыруга контроль

Программаны тормышка ашыру мөмкинлек бирәчәк:

- эчке базарда кече һәм урта эшкуарлык субъектларына көндәшлеккә сәләтлелекләрен күтәрергә;

-булган интеллектуаль һәм инновацион потенциалны сакларга һәм үстерергә;;

-кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мәгълүмати технологияләрне файдалануны киңәйтергә;

-эшкуарлык эшчәнлегенә кызыксынуны күтәрү хисабына халыкның эшлеклелек активлыгын үстерергә;

- кече һәм урта эшкуарлык субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын үстерергә;

- кече һәм урта эшкуарлык субъектларының финанс һәм матди ресурсларга керү (үтү) мөмкинлеген тәэмин итүче механизмнарны камилләштерергә;

- инфраструктура оешмалары тарафыннан эшкуарлыкка булышлык итү хезмәтләренең төрләрен киңәйтү һәм сыйфатын күтәрү юлы белән кече һәм урта эшкуарлыкка мәгълүмати-консультация ярдәме бирүне камилләштерергә;

-кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үзидарәлек заказларын үтәүгә җәлеп итәргә;

- кече һәм урта эшкуарлык үсешен тыеп торучы административ киртәләрне һәм каршылыкларны бетерүдә булышлык итүгә юнәлдерелгән механизмнарны көчәйтергә.

## 8. Йомгаклар һәм тәкъдимнәр (кушымтадагы таблица)

Балык Бистәсе муниципаль районында 2019 – 2023 елларга
КУЭ ны үстерү буенча төп ачкыч күрсәткечләр

| № п/п. | Күрсәткечләрнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 2019ел | 2020ел | 2021ел | 2022ел | 2023ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Индивидуаль эшкуарларны һәм үзмәшгуль гражданнарны кертеп, кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә мәшгульләр саны | кеше | 2 155 | 2 185 | 2 233 | 2 316 | 2 390 |
| 2 | ЭТП та кече һәм урта эшкуарлык өлеше | %; | 37,8 | 38,4 | 40,3 | 41,5 | 42,2 |
| 3 | Барлык дәрәҗәдәге бюджетларга КУЭ тан кергән салым һәм бүтән түләүләрнең тоткан урыны | %; | 29,1 | 30,4 | 30,9 | 31,6 | 32,1 |
| 4 | Катнашучылары фәкать КУЭ субъектлары гына булган сатып алуларның өлеше | %. | 46 | 51 | 53 | 57 | 59 |

**Төп ачкыч күрсәткеч (1) : 2019 – 2023 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында** кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү өчен инфраструктура объектлары булдыру һәм үстерү

| Ел | Үлчәү берәмлеге | Максатчан күрсәткеч (объектлар саны) | Ярдәмнәре белән максатчан күрсәткечкә ирешеләчәк конкрет чаралар исемлеге **(турыдан-туры йогынты)** | Ярдәмнәре белән максатчан күрсәткечкә ирешеләчәк конкрет чаралар исемлеге (**турыдан-туры булмаган йогынты**) |
|---|---|---|---|---|
| 2019 | Берәмлек | 5 | КУЭ субъектларына мөлкәти ярдәм;<br>Үзидарәлек дәрәҗәсендәге сәнәгать парклары булдыру һәм үстерү | Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә булышлык итү өчен аталган үзидарәлек мөлкәте реестрын алып бару һәм бастырып чыгару, КУЭ субъектларының эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле торак булмаган үзидарәлек биналарын сайлауда һәм арендалауда ярдәм;<br>Ташламалы шартларда үзидарәлек мөлкәте мәйданнарын өстенлекле тармаклар буенча КУЭ субъектларына арендага бирү. |
| 2020 | Берәмлек | 10 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү;<br>Үзидарәлек дәрәҗәсендәге сәнәгать парклары булдыру һәм үстерү. | Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә булышлык итү өчен аталган үзидарәлек мөлкәте реестрын алып бару һәм бастырып чыгару, КУЭ субъектларының эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле торак булмаган үзидарәлек биналарын сайлауда һәм арендалауда ярдәм;<br>Ташламалы шартларда үзидарәлек мөлкәте мәйданнарын өстенлекле тармаклар буенча КУЭ субъектларына арендага бирү. |
| 2021 | Берәмлек | 15 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү;<br>Үзидарәлек дәрәҗәсендәге сәнәгать парклары булдыру һәм үстерү. | Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә булышлык итү өчен аталган үзидарәлек мөлкәте реестрын алып бару һәм бастырып чыгару, КУЭ субъектларының эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле торак булмаган үзидарәлек биналарын сайлауда һәм арендалауда ярдәм;<br>Ташламалы шартларда үзидарәлек мөлкәте мәйданнарын өстенлекле тармаклар буенча |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | КУЭ субъектларына арендага бирү. |
| 2022 | Берәмлек | 20 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү;<br>Үзидарәлек дәрәҗәсендәге сәнәгать парклары булдыру һәм үстерү. | Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә булышлык итү өчен аталган үзидарәлек мөлкәте реестрын алып бару һәм бастырып чыгару, КУЭ субъектларының эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле торак булмаган үзидарәлек биналарын сайлауда һәм арендалауда ярдәм;<br>Ташламалы шартларда үзидарәлек мөлкәте мәйданнарын өстенлекле тармаклар буенча КУЭ субъектларына арендага бирү. |
| 2023 | Берәмлек | 25 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү;<br>Үзидарәлек дәрәҗәсендәге сәнәгать парклары булдыру һәм үстерү. | Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә булышлык итү өчен аталган үзидарәлек мөлкәте реестрын алып бару һәм бастырып чыгару, КУЭ субъектларының эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле торак булмаган үзидарәлек биналарын сайлауда һәм арендалауда ярдәм;<br>Ташламалы шартларда үзидарәлек мөлкәте мәйданнарын өстенлекле тармаклар буенча КУЭ субъектларына арендага бирү. |

**Төп ачкыч күрсәткеч (2) : 2019 – 2023 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында**

яңа гына керешүче (эш башлаучы) эшкуарларга ярдәм

| Ел | Үлчәү берәмлеге | Максатчан күрсәткеч (яңа гына керешүче эшкуарлар саны) | Ярдәмнәре белән максатчан күрсәткечкә ирешеләчәк конкрет чаралар исемлеге **(турыдан-туры йогынты)** | Ярдәмнәре белән максатчан күрсәткечкә ирешеләчәк конкрет чаралар исемлеге **(турыдан-туры булмаган йогынты)** |
|---|---|---|---|---|
| 2019 | Берәмлек | 6 | Үзидарәлек дәрәҗәсендәге сәнәгать парклары булдыру һәм үстерү;<br>Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең төрле ярдәм программаларында катнашуына | Эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү буенча хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын мәгълүмати тәэмин итү;<br>Эшкуарлык эшчәнлеген алып бару |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | булышлык күрсәтү | мәсьәләләре буенча КЭС ларына һәм физик затларга индивидуаль консультацияләр бирү. |
| 2020 | Берәмлек | 8 | Үзидарәлек дәрәҗәсендәге сәнәгать парклары булдыру һәм үстерү;<br>Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең төрле ярдәм программаларында катнашуына булышлык күрсәтү | Эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү буенча хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын мәгълүмати тәэмин итү;<br>Эшкуарлык эшчәнлеген алып бару мәсьәләләре буенча КЭС ларына һәм физик затларга индивидуаль консультацияләр бирү |
| 2021 | Берәмлек | 10 | Үзидарәлек дәрәҗәсендәге сәнәгать парклары булдыру һәм үстерү;<br>Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең төрле ярдәм программаларында катнашуына булышлык күрсәтү | Эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү буенча хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын мәгълүмати тәэмин итү;<br>Эшкуарлык эшчәнлеген алып бару мәсьәләләре буенча КЭС ларына һәм физик затларга индивидуаль консультацияләр бирү |
| 2022 | Берәмлек | 12 | Үзидарәлек дәрәҗәсендәге сәнәгать парклары булдыру һәм үстерү;<br>Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең төрле ярдәм программаларында катнашуына булышлык күрсәтү | Эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү буенча хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын мәгълүмати тәэмин итү;<br>Эшкуарлык эшчәнлеген алып бару мәсьәләләре буенча КЭС ларына һәм физик затларга индивидуаль консультацияләр бирү |
| 2023 | Берәмлек | 14 | Үзидарәлек дәрәҗәсендәге сәнәгать парклары булдыру һәм үстерү;<br>Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең төрле ярдәм программаларында катнашуына булышлык күрсәтү | Эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү буенча хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын мәгълүмати тәэмин итү;<br>Эшкуарлык эшчәнлеген алып бару мәсьәләләре буенча КЭС ларына һәм физик затларга индивидуаль консультацияләр бирү |

**Төп ачкыч күрсәткеч (3) : 2019 – 2023 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында** кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә норматив хокукый җайга салуны (көйләүне) камилләштерү

| Ел | Үлчәү берәмлеге | Максатчан күрсәткеч | Ярдәмнәре белән максатчан күрсәткечкә ирешеләчәк конкрет чаралар исемлеге (**турыдан-туры йогынты**) | Ярдәмнәре белән максатчан күрсәткечкә ирешеләчәк конкрет чаралар исемлеге (**турыдан-туры булмаган йогынты**) |
|---|---|---|---|---|
| 2019 | | | Норматив-хокукый җайга салу | КУЭ ны үстерү буенча норматив-хокукый акт проектларын эшләү; Үсеш (үстерү) мониторингы. |
| 2020 | | | Норматив-хокукый җайга салу | КУЭ ны үстерү буенча норматив-хокукый акт проектларын эшләү; Үсеш (үстерү) мониторингы. |
| 2021 | | | Норматив-хокукый җайга салу | КУЭ ны үстерү буенча норматив-хокукый акт проектларын эшләү; Үсеш (үстерү) мониторингы. |
| 2022 | | | Норматив-хокукый җайга салу | КУЭ ны үстерү буенча норматив-хокукый акт проектларын эшләү; Үсеш (үстерү) мониторингы. |
| 2023 | | | Норматив-хокукый җайга салу | КУЭ ны үстерү буенча норматив-хокукый акт проектларын эшләү; Үсеш (үстерү) мониторингы. |

**Төп ачкыч күрсәткеч (4) : 2019 – 2023 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында** кадрлар потенциалын ныгыту, эшкуарның уңай образын (тибын) булдыру

| Ел | Үлчәү берәмлеге | Максатчан күрсәткеч (катнашучылар саны) | Ярдәмнәре белән максатчан күрсәткечкә ирешеләчәк конкрет чаралар исемлеге (**турыдан-туры йогынты**) | Ярдәмнәре белән максатчан күрсәткечкә ирешеләчәк конкрет чаралар исемлеге (**турыдан-туры булмаган йогынты**) |
|---|---|---|---|---|
| 2019 | Берәмлек | 50 | Югары квалификацияле кадрлар әзерләү; Эшкуарлык эшчәнлеген популярлаштыру. | Кече һәм урта предприятиеләр хезмәткәрләренең квалификацияләрен күтәрү һәм һөнәри осталыкларын арттыру программаларын кертү; Тренерлар, эксперт һәм белгечләр катнашында |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | КУП ләр (кече һәм урта предприятиеләр) өчен укыту-өйрәтү форумнары, семинарлары оештыру;<br>ГМЧ да (гаммәви-мәгълүмат чараларыда) эшкуарлык тематикасын яктырту |
| 2020 | Берәмлек | 50 | Югары квалификацияле кадрлар әзерләү;<br>Эшкуарлык эшчәнлеген популярлаштыру. | Кече һәм урта предприятиеләр хезмәткәрләренең квалификацияләрен күтәрү һәм һөнәри осталыкларын арттыру программаларын кертү;<br>Тренерлар, эксперт һәм белгечләр катнашында КУП ләр (кече һәм урта предприятиеләр) өчен укыту-өйрәтү форумнары, семинарлары оештыру;<br>ГМЧ да (гаммәви-мәгълүмат чараларыда) эшкуарлык тематикасын яктырту |
| 2021 | Берәмлек | 50 | Югары квалификацияле кадрлар әзерләү;<br>Эшкуарлык эшчәнлеген популярлаштыру. | Кече һәм урта предприятиеләр хезмәткәрләренең квалификацияләрен күтәрү һәм һөнәри осталыкларын арттыру программаларын кертү;<br>Тренерлар, эксперт һәм белгечләр катнашында КУП ләр (кече һәм урта предприятиеләр) өчен укыту-өйрәтү форумнары, семинарлары оештыру;<br>ГМЧ да (гаммәви-мәгълүмат чараларыда) эшкуарлык тематикасын яктырту |
| 2022 | Берәмлек | 50 | Югары квалификацияле кадрлар әзерләү;<br>Эшкуарлык эшчәнлеген популярлаштыру. | Кече һәм урта предприятиеләр хезмәткәрләренең квалификацияләрен күтәрү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | һәм һөнәри осталыкларын арттыру программаларын кертү;<br>Тренерлар, эксперт һәм белгечләр катнашында КУП ләр (кече һәм урта предприятиеләр) өчен укыту-өйрәтү форумнары, семинарлары оештыру;<br>ГМЧ да (гаммәви-мәгълүмат чараларыда) эшкуарлык тематикасын яктырту |
| 2023 | Берәмлек | 50 | Югары квалификацияле кадрлар әзерләү;<br>Эшкуарлык эшчәнлеген популярлаштыру. | Кече һәм урта предприятиеләр хезмәткәрләренең квалификацияләрен күтәрү һәм һөнәри осталыкларын арттыру программаларын кертү;<br>Тренерлар, эксперт һәм белгечләр катнашында КУП ләр (кече һәм урта предприятиеләр) өчен укыту-өйрәтү форумнары, семинарлары оештыру;<br>ГМЧ да (гаммәви-мәгълүмат чараларыда) эшкуарлык тематикасын яктырту |

**Төп ачкыч күрсәткеч (5) : 2019 – 2023 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында**
сәүдә һәм куллану базарын үстерү.

| Ел | Үлчәү берәмлеге | Максатчан күрсәткеч (ваклап сату сәүдәсенең әйләнеше) | Ярдәмнәре белән максатчан күрсәткечкә ирешеләчәк конкрет чаралар исемлеге (**турыдан-туры йогынты**) | Ярдәмнәре белән максатчан күрсәткечкә ирешеләчәк конкрет чаралар исемлеге (**турыдан-туры булмаган йогынты**) |
|---|---|---|---|---|
| 2019 | млн. сум | 1908,98 | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга контроль . | Җир кишәрлекләрен рөхсәтсез урнаштырылган стационар булмаган сәүдә объектларыннан арындыру;<br>Куллану базары үсешенә мониторинг һәм анализ үткәрү;<br>Авыл хуҗалыгы продукциясен сату буенча ярминкәләр уздыру. |
| 2020 | млн. сум | 2031,06 | Стационар булмаган сәүдә объектларын | Җир кишәрлекләрен рөхсәтсез урнаштырылган |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | урнаштыруга контроль | стационар булмаган сәүдә объектларыннан арындыру;<br>Куллану базары үсешенә мониторинг һәм анализ үткәрү;<br>Авыл хуҗалыгы продукциясен сату буенча ярминкәләр уздыру. |
| 2021 | млн. сум | 2158,84 | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга контроль | Җир кишәрлекләрен рөхсәтсез урнаштырылган стационар булмаган сәүдә объектларыннан арындыру;<br>Куллану базары үсешенә мониторинг һәм анализ үткәрү;<br>Авыл хуҗалыгы продукциясен сату буенча ярминкәләр уздыру. |
| 2022 | млн. сум | 2266,78 | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга контроль | Җир кишәрлекләрен рөхсәтсез урнаштырылган стационар булмаган сәүдә объектларыннан арындыру;<br>Куллану базары үсешенә мониторинг һәм анализ үткәрү;<br>Авыл хуҗалыгы продукциясен сату буенча ярминкәләр уздыру. |
| 2023 | млн. сум | 2380,12 | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга контроль | Җир кишәрлекләрен рөхсәтсез урнаштырылган стационар булмаган сәүдә объектларыннан арындыру;<br>Куллану базары үсешенә мониторинг һәм анализ үткәрү;<br>Авыл хуҗалыгы продукциясен сату буенча ярминкәләр уздыру. |